**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 октябрендәге 3400 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә Благовещение соборыннан алып**
**Крестовоздвижение чиркәвенә кадәр хач йөрешен уздыру чорына**
**транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуларын чикләү турында**

2025 елның 4 ноябрендә Казан шәһәрендә Благовещение соборыннан алып Крестовоздвижение чиркәвенә кадәр хач йөрешен уздыруда иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булганда, түбәндәге участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуларын чикләүне кертергә:

1.1.1. 2025 елның 4 ноябрендә 07.00 сәгатьтән, хач йөреше автомобиль юлы буйлап узганнан соң хәрәкәт ачыла торган итеп, түбәндәге юллар буенча:

- Кремль урамы, Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәрге участокта;
- Профсоюз урамы, Чернышевский урамыннан алып Меңьеллык мәйданына кадәрге участокта;
- Беренче Май мәйданыннан төшү юлы, Кремль урамыннан алып Профсоюз урамына кадәрге участокта;
- Бауман урамы, Профсоюз урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;
- Меңьеллык мәйданыннан Батурин урамына чыгу юлында;
- Батурин урамыннан Кремль транспорт дамбасына чыгу юлында;
- Батурин урамы, Кремль транспорт дамбасыннан алып Дзержинский урамына кадәрге участокта;

- К.Маркс урамы, Лобачевский урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;

- Япеев урамы, Дзержинский урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта (кирәк булганда);

- Миславский урамы, К.Маркс урамыннан алып Дзержинский урамына кадәрге участокта;

1.1.2. 2025 елның 4 ноябрендә 07.00 сәгатьтән 09.30 сәгатькә кадәр Большая Красная урамының автомобиль юлы буенча, Япеев урамыннан алып Батурин урамына кадәрге участокта;

1.1.3. 2025 елның 3 ноябрендә 19.00 сәгатьтән 2025 елның 4 ноябрендә 09.30 сәгатькә кадәр Миславский урамының машиналар йөри торган юлы буенча, К.Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участокта (транспорт куюны тыеп);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыруда һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплауда ярдәм күрсәтергә;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**